РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» март 2019 ел г. Альметьевск № 394

2019 елның язгы чорында
Әлмәт шәһәренең җирле әһәмияттәге
гомуми файдаланулы
автомобиль юлларында транспорт
чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында

Әлмәт шәһәренең гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын язгы табигый –климат чорда сакланышын тәэмин итү, автомобиль юлларының конструктив элементлары сәләте кимүгә бәйле рәвештә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел 6 октябрь №131-ФЗ Федераль законның 16 маддәсе, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 ел 6 октябрь №131-ФЗ Федераль законның 16 маддәсе, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары юл эшчәнлеге һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрь №257-ФЗ Федераль законның 13, 30 маддәләре, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 ел 3 август № 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 ел 10 декабрь №196-ФЗ Федераль законның 14 маддәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк, муниципальара һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яисә туктату тәртибен раслау турында " 2013 ел 31 май №372 карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 15 апреленнән 14 маена кадәр Әлмәт шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланулы автомобиль юлларында тишле нормадан артык йөк төягән, аерым юл хәрәкәте билгеләре белән

билгеләнгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләмә кертергә.

2. Транспорт чарасыннан файдалану өчен рөхсәт ителгән йөкнең чик күләмен (1 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чорда җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буенча хәрәкәт гамәлдәге законнар нигезендә махсус рөхсәт язуы белән Әлмәт шәһәренең автомобиль юлларына зыянны каплау шарты белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Хәрәкәтне вакытлыча чикләү кагылмый:

- "Халыкара автомобиль йөртүне гамәлгә ашыруны дәүләт контроле турында һәм аларны үтәү тәртибен бозган өчен җаваплылык турында" 1998 елның 24 июлендәге №127-ФЗ Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла торган халыкара йөк ташучыларга ;

-автобуслар белән пассажирлар ташу, шул исәптән халыкара рейсларга ;

- азык-төлек продуктлары, хайваннар, дару препаратлары, орлык фонды, ашламалар, почта һәм почта йөкләрен ташучыларга ;

- ягулык ташучы транспорт чараларына (бензин, дизель ягулыгы, судно ягулыгы, реактив двигательләр өчен ягулык, ягулык мазут, газообразлы ягулык);

- табигый бәла-каза яисә башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен кирәкле йөк ташучыларга;

-билгеләнгән тәртиптә расланган исемлек нигезендә авария-торгызу һәм ремонт эшләрен башкарганда кулланыла торган юл-төзелеш һәм юл-эксплуатация техникасын, материаллар транспортлауны гамәлгә ашыручы транспорт чараларына;

- Федераль закон нигезендә хәрби хезмәт каралган федераль башкарма хакимият органнарының транспорт чараларына ;

- каты коммуналь көнкүреш калдыкларын җыю һәм ташу өчен файдаланыла торган махсуслаштырылган транспорт чараларына (чүп-чар);

- Әлмәт шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланулы автомобиль юлларын агымдагы карап тотуны тәэмин итүче юл-төзелеш оешмаларының транспорт чараларына.

5. "ТР Әлмәт муниципаль районының торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты" муниципаль автоном учреждениесенә (Сөләйманов З.А.) тәэмин итәргә:

- транспорт чараларының йөк ташуны чикләвен билгеләүче тиешле юл билгеләре кую;

- Әлмәт шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында хәрәкәт итүне чикләү турындагы гамәлдәге закон нигезендә вакытлыча йөрү өчен махсус рөхсәтләр бирү;

- махсус рөхсәтләр бирү пунктларын оештыру;

- әлеге карарның 1 пункты нигезендә кертелә торган хәрәкәтне вакытлыча чикләү чорына транспорт чараларының хәрәкәтен һәм авырлыгын үлчәү контролен оештыру.

6. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны "Альметьевский вестник" газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2019 елның 15 апреленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары А.Ә. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Район башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

1 нче кушымта
Әлмәт муниципаль районы
башкарма комитетының
«13» март 2019 ел № 394
карары белән расланган

Транспорт чарасына рөхсәт ителгән йөкләнеш

| №№ п/п | Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланулы автомобиль юллары исеме | Транспорт чарасының һәр күчәренә рөхсәт ителгән йөкләнеш: | | |
|---|---|---|---|---|
| | | бер күчәрле | ике күчәрле | өч күчәрле |
| | | тс (кН) | тс (кН) | тс (кН) |
| 1 | Әлмәт шәһәре | 6,0(60) | 5,0(50) | 4,0(40) |

Район башкарма комитеты җитәкчесенең
төзелеш буенча урынбасары А.Ә. Мөхәммәтҗанов